СОВЕТ СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КӨШКӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» сентябрь 2018 ел № 85

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Урта Көшкәт авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 18 сентябрендәге 83 номерлы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карары, «Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 18 сентябрендәге 10 номерлы Урта Көшкәт авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2019 елда Урта Көшкәт авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 400 сум

күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Түнтәр авылында: юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү;

- Урта Көшкәт авылында: юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, янгынга каршы гидрант урнаштыру;

- Пор-Кутеш авылында: юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү;

- Сала-Көшкәт авылында: суүткәргеч торбаны ремонтлау һәм койма кую

**ЮК** **ӘЙЕ".**

3. Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карары нигезендә, аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында һәм pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар аңа имза куелган көннән үз көченә керә.

Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Ю.М. Перфилов